ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Мәгариф турында” 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $25^1$ статья өстәргә:
“$25^1$ статья. **Педагог хезмәткәрләргә квалификация категориясе билгеләү максатларында аттестация үткәрү**

1. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган һәм Татарстан Республикасы карамагындагы оешмаларның педагог хезмәткәрләренә, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган муниципаль һәм хосусый оешмаларның педагог хезмәткәрләренә квалификация категориясе билгеләү максатларында аттестация Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы төзи торган аттестация комиссияләре тарафыннан үткәрелә, моңа әлеге статьяның 2 өлешендә каралган очраклар керми.

2. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган һәм Татарстан Республикасы карамагындагы оешмаларның педагог хезмәткәрләренә, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган муниципаль һәм хосусый оешмаларның педагог хезмәткәрләренә квалификация категориясе билгеләү максатларында аттестация үткәрү өчен аттестация комиссияләре түбәндәгеләр тарафыннан төзелә:

физик культура һәм спорт өлкәсендә уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган оешмаларга карата – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең физик культура һәм спорт өлкәсендә вәкаләтле органы;

медицина белеме һәм фармацевтика белеме буенча уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган оешмаларга карата – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органы;

сәнгать өлкәсендә уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган оешмаларга карата – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 6 июле
№ 54-ТРЗ